**Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

Сезгә 2026 елның 7 июленнән 2026 елның 29 июленә кадәр җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итәбез.

Гавами тыңлаулар түбәндәге проектлар буенча билгеләнә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре шәхси торак төзелеш зонасында «кибетләр» (Ж-1) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали авылы, Молодежная ур., 1А ж/к адресы буенча урнашкан 485 кв.м. мәйданлы, кадастр номеры 16:33:180102:2354 булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

Гавами тыңлауларны үткәрү вакытын һәм урынын 2026 елның 22 июлендә 11.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында билгеләргә. (Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске Шигали авылы, Центральная ур., 45 й. (алга таба – Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

Проектлар экспозициясен Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, 2026 елның 13 июленнән 2026 елның 22 июленә кадәр эш көннәрендә 10 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 00 минутка кадәр (ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты 12 сәгать 00 минуттан 13 сәгать 00 минутка кадәр) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб – адрес буенча оештырырга (https://pestreci.tatarstan.ru/zhizn-poseleniya-6828329.htm) «проектлар экспозициясе» вкладкасында.

Экспозиция һәм гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыруның бөтен чоры дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар проектларга кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручы адресына түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Шигали авылы, Центральная урамы, 45 йорты, e-mail: shig.pes@tatar.ru;

- Татарстан Республикасы, Шигали авыл җирлеге, Шигали авылы, Центральная ур., 45 йорт адресы буенча Шигали авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язып кую юлы белән;

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдим яки искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бирелергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификацияләү максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, яшәү (теркәлү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, тору урыны һәм адресы – юридик затлар өчен) мондый белешмәләрне раслаучы документлар белән бергә тапшыралар.

Тиешле җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше

булган урыннарның хокук ияләре булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук тиешенчә мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннар турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә аларның хокукларын таныклаучы, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар.

Җунле тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга ризалыгын бирәләр.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге мәгълүмат стендларында «Вперед» («Алга») газетасында бастырып чыгарырга.

Питрәч муниципаль районының
Шигали авыл җирлеге
башлыгы урынбасары

Р.Р. Фәйзуллин